ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Юр.адрес:423984, РТ, Муслюмовский район, с.Октябрь, ул.Молодежная, д.3а,
Факт.адрес:423984, РТ, Муслюмовский район, с.Октябрь, ул.Центральная, д.33А,
Okt.Mus@tatar.ru тел. 8(8-5556) 3-51-26
ИНН 1629004040, КПП 162901001, ОГРН 1021687005346, ОКАТО 92242860001

Октябрь авылы «_30_»___01___2020 ел

**КАРАР № 1**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, «2020 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елның 1 февраленнән Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны үз өстемә алам.

Октябрь авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: Ханнанов И.М.

Мөслим муниципаль районы
Октябрь авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесенең
2020 елның 30 гыйнварындагы
1 нче санлы карарына
1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү. | 3311,44 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү. | 968,39 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү). | 1845,03 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Мөслим муниципаль районы
Октябрь авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесенең
2020 елның 30 гыйнварындагы
1 нче санлы карарына
2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** *(сум)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | 0,00 |
| 2. Кәфенләү. | 940,24 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү. | 2401,6 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү. | 993 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү). | 1790,02 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |